**Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Керкәле авыл җирлегенең Керкәле торак пунктында гражданнар җыены карары**

2024 елның 23 ноябре № 7

**Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Керкәле авыл җирлегенең Керкәле торак пунктында 2025 елда гражданнарга үзара салым кертү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары нигезендә, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы белән, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 22 ноябрендәге 909 номерлы карары белән расланган (29.11.2023 №1532 редакциясендә) Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына гражданнарның үзара салым акчаларын җәлеп итеп гамәлгә ашырыла торган җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибенең 2 пункты белән, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Керкәле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 24.1 маддәсе белән, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Керкәле авыл җирлегенең Керкәле торак пункты гражданнар җыены КАРАР БИРДЕ:

1. 2025 елда Лениногорск муниципаль районы Керкәле авыл җирлегенең Керкәле торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәм яшәү урыны Керкәле авыл җирлеге чикләрендә урнашкан һәр балигъ булган кешедән, балачактан инвалидлардан, шулай ук I төркем инвалидлардан, көндезге формада укучы студентлардан, Бөек Ватан сугышы һәм сугышчан хәрәкәтләр ветераннарыннан; Бөек Ватан сугышы һәм сугышчан хәрәкәтләр ветераннарының тол хатыннарыннан тыш, 2025 елда 500 (Биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

1) торак пункт территориясен төзекләндерү (триммер һәм бензопила өчен ягулык-майлау материаллары сатып алу; МТЗ-82.1 тракторын тоту һәм аңа хезмәт күрсәтү (дизель ягулыгы, май, фильтр сатып алу);

тракторчы хезмәтләре өчен килешү буенча түләү(территорияне коры-сары һәм чүп үләннәреннән чаптыру, полосаларны минеральләштерү һәм сөрү, урамнарны кардан чистарту һәм башка эшләр);

2) су белән тәэмин итү һәм су агызу системаларын, су башняларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны,транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итә торган башка инженерлык корылмаларын проектлау, ремонтлау (сууткәргечләр төзү һәм ремонтлау, Керкәле авылы халкын эчә торган су белән тәэмин итү).

3. Әлеге карарны түбәндәге адрес буенча урнашкан мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә: Татарстан Республикасы, Лениногорск районы, Керкәле авылы, Совет урамы, 93 йорт, Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында (http://leninogorsk.tatarstan.ru) «Авыл җирлекләре» бүлегендә һәм

Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (https://pravo.tatarstan.ru/) бастырып чыгарырга.

Лениногорск муниципаль районы
«Керкәле авыл җирлеге» башлыгы,
җыенда рәислек итүче Л.И.Бигманов